**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ШЕШМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

ул.Комарова, д.14, с.Шешминская
Крепость, 423104

Комаров урамы, 14 йорты,
Шешминка Крепосте авылы,
423104

тел./факс(84396) 2-36-54 email: Shesh.Cmn2@tatar.ru

---

№46 19.05.2022ел

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Шешминка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2022 елның 31 мартындагы 103 номерлы «Муниципаль районның авыл җирлекләренә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегенә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Шешминка авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш

кагыйдәләрен эшләү, үзгәрешләр кертү өлешендә вәкаләтләрне тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Шешминка авыл җирлеге башлыгына муниципаль район башлыгы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Шешминка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе: Шәйхетдинов М.Д.